

ҖИР ЙӨЗЕНДӘ ТЫНЫЧЛЫК ,ДУСЛЫК, МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК, ГАДЕЛЛЕК БУЛСЫН!

№4 апрель май

2021 нче ел

# МӘКТӘП СУЛЫШЫ

## Тукай гомере-мәңге өзелмәс җыр

Габдулла Тукай –татар халкының бөек шагыйре. Бу дөньяда Тукайны белмәгән, аның бер шигырен булса да укымаган татар кешесе юктыр. Ул нибары 27 ел гына яшәп, бик зур иҗади мирас калдырган. Тукай хезмәтләре 50дән артык телгә тәрҗемә ителгән.

Мәктәбебездә халкыбызның бөек шагыйре Г. Тукайның 135 еллыгына багышланган искә алу кичәсе үтте. Балалар шагыйрьнең шигырьләрен, әкиятләрен сәнгатьле итеп яттан сөйләделәр, Тукайның тормыш, иҗат юлын куңелләрендә яңарттылар, олуг җырчыбыз Зөһрә Сәхәбиева башкаруында җырлардан видео карадылар.

“Тукай әкиятләре дөньясында” рәсемнәр бәйгесендә башлангыч сыйныф укучылары бик теләп катнаштылар. Сөекле шагыйребез әсәрләре буенча төшерелгән мультфильмнар карадылар.



## Бу санда

*Тукай гомере-мәңге өзелмәс җыр*



*Әлифба бәйрәме*




*Сабантуй*




Тулырак мәълүматны https://vk.com/club144505055 сылтамасы аша кереп карый аласыз.

# Әлифба бәйрәме




"Балачак иленең кабатланмас бәйрәмнәреннән берсе нинди бәйрәм?" - дип сорасалар, бер дә икеләнмичә "Әлифба бәйрәме" дияр идем мин. Җир йөзендә кем генә булмасын, кайда гына эшләмәсен, ул зур дулкынлану белән үзенең нәни кулларына тәүге тапкыр Әлифба китабын алганын искә төшерә. Чөнки һәркемнең дә белем дөньясына беренче адымы Әлифбадан башлана бит.

Безнең мәктәптә дә бик күңелле генә "Әлифба бәйрәме" узды. Бу бәйрәм - укучылар өчен дә, укытучылары өчен дә һәм инде укырга, язарга өйрәнгән укучыларның әти-әниләре өчен дә зур тантана булып тора. Әлифба белән беррәттән укучыларның барысы да укырга, язарга, матур итеп сөйләргә, әдәпле булырга, өлкәннәрне һәм кечкенәләрне ихтирам итәргә, коллектив белән дус яшәргә, ярдәмчел булырга өйрәнделәр. Шулай ук укчылар укырга, язарга гына түгел әкиятләрне сәхнәләштерергә дә өйрәнделәр. Алар Габдулла Тукайның әкиятләрен матур итеп уйнадылар, биеделәр, җырладылар. Чыннан да бу аларның беренче зур җиңүләре булды. Алдагы көннәрдә дә укучыларыбыз шундый зиһенле һәм тырыш, сау-сәламәт булсыннар, дигән теләктә калабыз!







# *Тәмле булсын*

***Бүген бәйрәм табынына чәк-чәк әзерлибез.***
***Чәк-чәк** – татар халкының табын күрке булган милли ризыкларының берсе.*

**Камыр өчен:**

5 йомырка, 1аш кашыгы сөт, 2 аш кашыгы су, ½ чәй кашыгы чәй содасы, ½ чәй кашыгы тоз, кирәгенчә он.

**Болгату өчен:** 1 стакан шикәр комы, ½ стакан бал.



Барысын бергә кушып болгатабыз да камыр басабыз.
Йомшак сыгылмалы камырны 25-30 минутка кабарырга куябыз.
Шуннан соң калынлыгы 2-3 мм булган җәймәләр әзерлибез. Җәелгән камырны 3 см зурлыктагы тасмаларга, аннан соң бау сыман нечкә кисәкләргә кисәбез. Тирән табага көнбагыш мае салып, аны утка куябыз. Май кызганнан соң камыр кисәкләре алтынсу төскә кергәнче кыздырабыз. Майда кызган камыр кисәкләрен кайнап чыккан бал һәм шикәр комы катнашмасы белән яхшылап болгатабыз һәм тәлинкәләргә салып конус формасына китерәбез.








***Милли ризыкларыбызны пешереп, туган телебезне өйрәнеп, гореф-гадәтләребезне саклап, дуслыкта-туганлыкта яшик!***



# Сабантуй

*Милли бәйрәмнәр*

Сабантуй- бу бәйрәмдә хезмәт халкының бик борынгыдан килгән күркәм гадәтләре, уен-җырлары, йолалары бергә кушыла. Ул бик борынгы да, шул ук вакытта, олысын-кечесен, туганнарны, сыйныфташларны, милләттәшләребезне бер мәйданга җыйный алган бәйрәм.

Сабантуй, гадәттә, язгы кыр эшләре тәмамлангач, июнь башында үздырыла. Ә менә мәктәбебезнең башлангыч сыйныфлары майның кояшлы бер көнендә кечкенә сабантуй бәйрәмен гөрләтеп уздырып та куйдылар. Мәктәп мәйданчыгы балаларның шат, дәртле авазларына күмелде.

Күмәк татарча бию дисеңме, капчык киеп яки кашыкка йомырка салып йөгерүме, ымсындырып торган чүлмәкне күңел күзе белән күреп, кулындагы колга белән челпәрәмә китерүдән ләззәт алумы- барысы да сабантуйның күңелле мизгелләре булды. Күзне бәйләп бауга эленгән призларны кайчы белән кисү аеруча ошады укучыларга. Укытучылары белән кулга- кул тотынышып рәхәтләнеп биеделәр, җырладылар. Бер генә укучы да бүләксез, игътибарсыз калмады.













# “Татар кызы, татар егете- 2021”

Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында район күләмендә “Татар кызы, татар егете-2021” бәйгесе узды. Бәйгенең максаты- татар халкының милли мәдәниятен, гореф-гадәтләрен һәм телен саклап калу, үстерү, үсеп килүче буынга мирасны тапшыру. Мәктәбебездән 8 нче сыйныф укучылары Садриев Раиль  һәм Петрова Снежана катнаштылар. Укучылар үзләренең визит карточкаларын, иҗади номерларын, милли костюмнарын күрсәттеләр. Петрова Снежана 3 урынга лаек булды. Иң талантлы егет исемен Садриев Раиль яулады. Афәрин!










## Ә син белә идеңме?



# Чулпылар

“Татар кызын иң элек ишетәсең, аннары гына күрәсең” – дигәннәр элекке заманнарда. Чыннан да, татар хатын-кызларының бизәнү әйберләре шулкадәр күп булган - атлаган саен чылтырап торганнар алар.



Барыннан да бигрәк чәч толымнарына кушылып үрелгән чулпылар чылтыраганнар. Чулпының махсус ясалган алкаларына тасма керткәннәр, чәч толымына әнә шул тасмаларны кушып үргәннәр. Койрык калдырмыйча чулпы үрү зур осталык булып саналган. Чулпы үзе тәңкәләрдән торган. Ясалышы ягыннан алар күптөрле булганнар. Тәңкәләр чулпыга икешәр-өчәр, алтышар, хәтта тугызар итеп тә тезелгәннәр. Шулай итеп ясалган авыр чулпылар “көянтәләр” тәшкил иткән һәм берьюлы ике толымга кушып үрелгән. Чулпы авырлыгыннан чәчләр тизрәк үсә дип уйлаганнар. Шулай ук тәңкәләрнең чыңлавы явыз рухларны да куркыта дип ышанганнар.

Чулпыны бар кеше дә ясый алмаган. Аларның үз осталары булган. Бу осталык буыннан-буынга, якын туганнарга тапшырылып килгән. Аның уникаль техник серләрен кадерләп саклаганнар, бу серләрне Казан һәм якын-тирә авыл зәркәннары гына белгән. Тора-бара зәркан сәнгате киң тармакланып китә. Осталар арасында татар зәрканнары да була, алар зәркан серләренә өйрәтү өчен чакырылалар. 19 гасыр ахырына зәркән сәнгате әкренләп югала. Ләкин, сөенечкә каршы, хәзерге көндә чулпыларны, гомумән, татар бизәнү әйберләрен ясау торгызыла. Аларны ярминкәләрдә, хәтта игълан сайтларында да күреп була. Якын киләчәктә, бәлки, без дә әбиләребез кебек чулпырыбызны тагып чылтыратып йөрербез, татар кызы килгәнен еракган белдереп торырбыз дип ышанабыз.

**Гәҗитне басмага әзерләделәр:**

6 нчы сыйныф укучылары

Җитәкчеләре: Хөсәенова Л.Т.

***Сездән язмалар көтеп калабыз!***